Мин, Ибәтуллина Шәргыя Ибәтулла кызы, Бәзәкә авылында 1928 нче елның 24нче февраль көнне дөньяга килгәнмен.

Сугыш елларында 7 класс тәмамлап колхозда эшләдем. 1950 нче елда Алабуга культура – агарту училищесына укырга кердем. 1953 елдан башлап Бәзәкә авылы клубында 6 ел хезмәт куйдым. 1959 нчы елдан Бәзәкә балалар бакчасында мөдир булып эшләдем. 1963 нче елның сентябрендә авыл советына эшкә күчтем. 25 ел баш бухгалтер булып эшләп 1988 елда эштән туктадым. Хәзер лаеклы ялда, сугыш елы ветераны.

## Фәрәхетдин бәете

Мине бүген авыл халкы
Олы юлга озатты
Шәргыям озатып калды
Авыр булды шул чаклы.

Аерылулар авыр булды
Төштә күрдем үләсемне
Унбишендә җаным тынды
Авыртуыма өч ай тулды.

Балаларым, күз нурларым
Рәнҗетмәгез, анагызны!?
Һәрчак искә төшерерсез!?
Ябык рәссам атагызны.

Аерылуны уйлап яттым
Ник бер җирем авыртса соң
Төшемдә дә рәсем ясыйм
Пумаланы кул тотмый шул.

Күп яшәдек дөньялыкта
Авырлыклар артта калды
Килде бер көн(Газраил җанны алды)
Бар семьям хәйран калды.

Тормышыма зарланмадым
Бер үкенеч тә калмады
Бар да бетте, Олы юлга киттем
Әйтер сүзләрем калмады.

Мин китте дип юксынмагыз
Яныгызда анагыз бар
Дус булыгыз, өч күз нурым

Сезгә шул васиятем бар.

Дөньялыктан бер киткәчтен
Кире кайтулар юк икән.
Серләшергә, акыл белән сөйләшергә
Газиз әниегез исән.

Мин әтидән 13 яшьтә калдым
Авырлыклар әни белән миндә булды
Ә сез – ятимлекне күрмәдегез
Үстерегез балаларны хөрмәт итеп.

Бу сүзләрне әйткән чакта күңлем тулды
Мин бит сезгә бер авыр сүз дә әйтмәдем
Үземә авыр чакларда да “ах” димәдем.
Дус яшәгез исән булмасам да
Мин белеп ятамын дөнья хәлләрен.

Көннәр үтә, төннәр үтә
Бер көн килә, пар канатыңберсе сынып
Дөньялыктан алып китә.
Әйтелмәгән сүзләремне хәзер әйтәм
Кермәсен туганнар арасына “кире беткән”.

Минем калган эшләремне
Дәвам ит син, улым Рәис
Оныткачы, әйтеп куям
Төгәллә син иртә һәм кич.

Хаҗинур бәете

Гыйнвар ае. Карлар ява.
Кар ява, яңгыр ява.
Авылдашлар Хаҗинурны.
Зиратка озата бара.

Бар иде авылыбызның
Нурлы бер Хаҗинуры
Йөзендә һәрчак елмаю.
Гүя, җәннәт хозуры.

Шәһәрдә яшәсә дә ул,
Авылын онытмады

Ярый әле нәселендә
Рифнур бар – оныклары.

Җитмеш яшькә дә җитмичә
Китте безнең арадан.
Шулай тиз юкка чыгудан
Барыбыз аптыраган.

Үзенә юл ачып куйган
Капка төбен күрәгән.
Бәлки, төшендә күргәндер.
Бүген үләм димәгән.

Фәттах бабай җимешләре
Сигез данә иделәр
Күз ачып йомганчы менә
Бер башка кимеделәр.

Күршеләре, туганнары
Озатырга җыелды
Сирәк күрә авыл халкы
Мондый “олы” җыенны.

Дөньялары бозык тик шулай да
Иманлы җан таба кыйбласын
Йөрәк дулкынлана, и Ходаем
Изгеләргә бәхет юлласын.

## Язмышлардан узмыш юк икән.

Яшь тә дүрт айлык баласын
Гүзәл ана ташлап китте
Ходай шулай яраткандыр
Бер нишләп тә булмый инде.

Еллар үтте, акты сулар
Гөрләп яшәү артта калды
Килде бер көн, сулыш бетте
Ходаем җанымны алды.

Пар канатлы кошлар кебек
Очып йөрдек авылларда
Язмышларны белмибез шул
Килеп чыга давыллар да.

Исән калган җан дусларым
Бу язмышны күрмәгез сез
Рәнҗетмәгез аналарны,
Яратыгыз балаларны.

Айдар улым, син сеңелеңне
Ярата күр минем кебек
Әбиеңә зур терәк бул
Әти Мансур, син дә ишет.
Газиз анам, атам, Зиннур
Бу балалар сезгә калды
Октябрьнең бер көнендә
Ходаем җанымны алды.

Бар туганнар җыелдылар
Хушлашырга минем белән
Күзләрем йомык булса да
Гәүдәм әле ята исән.

Эштәге дуслар җыелып
Хушлашырга килделәр дә
Әни белән кочаклашып
Җылап чыгып киттеләр дә

Ә мин ятам, эх дусларым
Сез бу язмышны күрмәгез
Нарасыйларны калдырып
Аналарга зур кайгылар китермәгез

Зират капкаларын ачып
Керәселәр дә бар бит
Анда кергәч тар кабердә
Җавап бирәсе дә бар бит.

Ташлама, әнкәй, ташлама
Мине изге догаңнан
Ташласаң изге догаңнан
Мин тыныч ята алмам.

## Бәйрәмнәрнең иң зурысы.

Бу шигырьнең авторы Саимә Әхмәтнәби кызы Насыйрова. Ул тумышы белән Бәзәкә авылыннан. Шунда гомер кичергән. Бөек Ватан сугышы башланган елны туган. Әтисе аңа ике яшь булганда һәлак була. Саимә ханым – “Кама”

авыл хуҗалыгы кооперативы сыер савучысы. 30 елдан артык гомерен яраткан эшенә багышлый.
Иртәгә Җиңү көне дигән көнне , ягъни 8 майда, әнисе Миңнебаян апа Шиһабетдинова вафат булган. Шуның якты истәлегенә ул шушы язманы иҗат иткән.
- Бөек Ватан сугышында тормыш иптәшләрен югалтып, үз җилкәләрендә бөтен авырлыкларны кичергән тол әниләргә, бүгенге көнгә кадәр сөйгән егетләрен көткән апаларга бәйрәм бүләгем, мәрхүмәләргә догам булып ирешсен иде бу шигырем, - ди Саймә апа.

Бәйрәмнәрнең иң зурысы –
Әниләрнең бәйрәме.
Куеп китәм кабереңә
Тере чәчәк бәйләме.

...Яулыкларың ак синең
Чәчләрең дә ак синең
Фәрештәгә охшатамын
Күңелләрең саф синең.
Иңнәреңә баулар асып
Сукаларны тарткансың.
Тәүлек буе басуларда,
Буразнада яткансың.

Ялгызлыктан зарланмадың
Авырлыктан курыкмадың.
Саф корычка охшатамын-
Сынмадың, сыгылмадың.

Картайдың бит инде, әнием
Һаман көтәсеңмени?
Кайтмаганын бик белсәң дә
Өмет итәсеңмени?

Бәйрәмнәрнең иң зурысы-
Әниләрнең бәйрәме.
Башым иям алларыңда
Тезләремә тезләнеп.

Хат ташучы куеп китте
“Без вести” хәбәрен.
Кара кәгазь тоттыргачтын
Бетеп китте хәлләрең...

Куеп китәм кабереңә

Тере чәчәк бәйләмен....